Балалар журналы

ISSN 0868-4545

Салават күпере



Бәйрәмнәрегез котлы булсын, малайлар, кызлар!

© "Салават күпере", 2002 ел

Айтуган урам буйлап атлый. Ак авылга зәңгәр күктән ниләргәдер өметләндереп, ниләргәдер ымсындырып якты нур сибелә. Малайның кәефе шәп. Бүген – бәйрәм. 23 Февраль – Ватанны саклаучылар көне. Әтиләр, ир-егетләр, малайлар бәйрәме. Айтуган бәйрәме. Ул да булачак солдат бит. Әнә каршыга күрше кызы Миләүшә килә. Шул кыз бит әле былтыр: «Сез – малайлар – 8 Мартта безнең аркада ял итәсез», – дип мактанып торган иде. Ә сезгә – малай-шалайларга – бәйрәмегез көнне ял да бирмиләр, имеш. Ниһаять, быелдан башлап 23 Февраль дә – ял көне. Менә бит Айтуганга да Миләүшә алдында мактанып алырга җай чыкты. Хәер, ул тел бистәсенең «Сезнең бәйрәм – бәйрәммени, вәйт безнең бәйрәм – бәйрәм», – дип чәрелдәячәге көн кебек ачык. Хаклымы – юкмы, мактануын белә ул. Шулай уйланып барганда, Миләүшә үзе борылып эндәшмәсенме:

– Бәйрәмегез котлы булсын, Айтуган!

– Рәхмәт, Миләүшә. Сине дә безнең бәйрәм белән. Юк, 8 Март белән!

Көн тагын да яктырып китте.

Һавада яз исе.

Юлларда, түбәләрдә, тау түбәләрендә яз.

Җирдә яз.

Күңелдә яз...



Рәссам Фәридә ЗӨЛКАРНӘЙ.



Ләбиб Лерон

Гали батыр

Рәссам
Фәрит Муллахмәт

Шалтмылтфильм

Һәр авылның чибәр кызы,
Матур малае була.
Көч-гайрәте ташып торган
Батыр малае була.

Бездә дә бар шундый батыр –
Исеме Гали аның;
Иң яраткан энесе ул
Апасы Галиянең!



Гали батыр һич курыкмый
Беркемнән, бернидән дә...
Агач мылтык янда булса,
Курыкмый бүредән дә!




Гали батыр күренүгә,
Барчасы да куркалар:
Усал этләр, ата казлар,
Голдыр-голдыр күркәләр...



Гали батыр иң-иң усал
Үгезне дә җиңәлә.
Һич тиктормас яшь тайны да
Ул берүзе җигәлә.




Гали батыр төнлә тышка
Курыкмыйча чыгала,
Мәктәптәге һәр малайны
Бармак төртеп егала.



Гали батыр ега ала
Әзмәвердәй Нилне дә.
Бер сугуда аударала
Фил кадәрле филне дә!




Крокодилны очратсамы?! –
Җиңә ала аны да.
Карап торса, ул җиңгәнне
Раслар иде Бану да.



Арысланнар, юлбарыслар
Гали өчен чүп кенә:
Шундук тәгәрәп китәләр,
Кулы тисә чүт кенә!



Гали батырны күрсәләр,
Качсалар да качмыйлар:
Юлбасарлар һәм пиратлар
Дер калтырый башлыйлар.



Гали батырны күрүгә
Син башыңны иярсең.
Сокланыплар карап аңа:
«Терминатор!» – диярсең...




...Бу дөньяның иң батыры
Булыр безнең чорларда,
Курыкмаса әгәр Гали
Өйдән тышка чыгарга.





Кадерле дусларым! Сез инде тәүлекнең 24 сәгать икәнен беләсез. Ә нишләп соң тәүлек нәкъ менә 24 сәгать? Бүген без шул сорауга җавап табарбыз.

Тәүлек



Сез йокыдан уянгач та әниегезгә, әтиегезгә, туганнарыгызга ни дисез? Әлбәттә, «Хәерле иртә!» – дисез. Шулай итеп яңа көн башлана.

Бер-берегезгә тыныч йокы теләп йокларга ятканчы, иртәдән кичкә кадәр сез бик күп эшләр эшләргә өлгерәсез, шулай бит.


Әйдәгез әле, исегезгә төшерегез һәм язып куегыз, гадәттә сезнең көнегез ничек үтә? Сәгать ничәдә йокыдан торасыз, ничәдә төшке ашны ашыйсыз?.. Яздыгызмы? Менә сез үзегезнең көндәлек эшләрегезнең тәртибен билгеләдегез. Шушы тәртип буенча яшәсәгез, бөтен эшләрегезне дә вакытында эшләп бетерерсез.

Якты көнне караңгы төн алмаштыра. Тагын таң ата, көн килә... Чөнки Җир шары үз күчәрендә әйләнеп тора. Җир шарының без торган ягы кояшка караганда, көн була, ә ул кояштан борылгач, төн җитә. Җиргә үз күчәрендә бер кат әйләнеп чыгар өчен 24 сәгать вакыт кирәк. Менә шул - тәүлек була да инде.

Төн-иртә-көн-кич – бер тәүлек

Бер үк мизгелдә Җирнең төрле урыннарында сәгать төрле вакытны күрсәтә. Әйтик, Нью-Йоркта сәгать иртәнге 7 булганда, Лондонда төн уртасы - төнге 12.

Бездә – Татарстанда – сәгать көндезге 3 булганда, Башкортостанда – көндезге 5, Владивостокта – төнге 12 була.



Казанда кичке 6 булганда Уфада сәгать ничә? Ә Владивостокта?


Сезнең таң атканны күзәткәнегез бармы? Көнчыгыштан Кояш күтәрелгәндә яңа көн башлана. Көн дәвамында Кояш күтәрелә дә күтәрелә.

Аннан көнбатышка таба төшә башлый. Ә төнлә Ай һәм йолдызлар шул ук юлны үтәләр. Алар җир тирәли әйләнеп йөриләр төсле, ләкин чынлыкта, Җир үзе космик киңлектә әйләнеп тора.

Көн үзәгендә Кояш күкнең иң биек ноктасына җитә. Бу вакытта Җирнең без торган ягы тулысынча Кояшка борылып беткән була.

Көн үзәге – тәүлекнең иң якты һәм җылы вакыты.





Рәссам Диләрә НӘҮРУЗОВА



Кышкы урманда

Урман кыш көне дә бик матур ул. Әйе, әйе, без гадәттә чәчәкле, җиләкле җәйге урман гына гүзәл була дип уйлыйбыз. Чынлыкта, ялгышабыз, шулай уйлап хаталанабыз икән без. Бар син кышкы урманга, күр аның матурлыгын! Калын кар белән капланса да, агачларның яфраклары коелып бетсә дә, кышкы урманда тормыш кайнап, гөрләп тора.

Әлбәттә, кош-кортларның күбесе ояларында утыра. Мәсәлән, урманны калын кар каплап алгач, тиен куышыннан чыгып йөрергә яратмый. Ул аю кебек кышкы йокыга ук талмый талуын. Өендә йокымсырап утыра бирә. Тамагы ачса, урманга чыгып чикләвек алып керә. Әйе, әйе, кар астында көздән җыеп куйган сые бар аның.

Песнәк, кычыткан чыпчыгы кебек кошларның салкыннан бозланган агач каерыларын чукырга көчләре җитми, әлбәттә. Ләкин алар да җаен таба: тукранның тамагы ачканын гына көтеп утыралар. Тегесе бозланган агач каерысын үзенең каты томшыгы белән бик ансат кына тишә. Ә анда исә – җим. Шуңа күрә дә бу кошлар тукран артыннан ияреп йөриләр, барыбер өлеш чыгачак бит! Тукран саран түгел ул, агач кортларын башка кошларга да калдыра.

Кычыткан чыпчыклары кышкы салкын төннәрдә бергәләшеп иске ояларга кереп качалар. Бергә-бергә булгач, тиз җылыналар, туңмыйлар. Ә инде берәр көн азык-җим таба алмыйча ач калырга дучар булсалар, алар үлә.

Яфраклы агачларны кыш көне дә танып була. Кәүсәләренең формаларына, ботакларына гына игътибар итәргә кирәк.

Төлке үзенең өне каршында утыра. Караңгы төшкәнен көтә ул. Кич җитүгә азык эзләпауга китәчәк.

Кабан дуңгызлары азыкны кар астыннан эзли. Ач калсалар да исләре китми, аларның майлары калын.

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Будәнә белән Төлке

Җәйнең иң матур вакытларында Будәнә белән Төлке дус булып йөрергә сүз бирешкәннәр, ди. Бу ике дус йөриләр икән, йөриләр икән, йөри торгач, Төлке Будәнәгә зарланыбрак болай диде ди:

– Әй, иптәш! Минем карыным бик ачты. Нәрсә генә табып ашарга инде? – дигән.

Будәнә аңа җавап биреп:

– Әллә син миңа ышанмыйсыңмы? Мин синең тамагыңны туйдыра алам бит, – дигән.

Төлке:

– Йә, алайса, туйдыра алсаң, туйдырып кара инде, ничек итеп туйдырырсың икән, – дигән.

– Әйдә, киттек әнә теге юл буена, – дип, калын арыш уҗымы арасыннан Будәнә Төлкене бер юл буена алып килгән.

Ярый. Юл буена килеп җиткәч, ике дус тагын да киңәш итешкәннәр:

– Менә син, шуннан юл читеннән генә качып-посып юл өстен күзәтә тор. Ә мин юлның үзенә чыгам, – дигән Будәнә.

Төлке, арыш уҗымы арасына ятып, юл өстен күзәтеп тора башлый. Күрә: бер бик яхшы гына киенгән-ясанган ир белән кулына төенчек тоткан хатын кунактан кайтып киләләр икән. Хатын иренә эндәшә:

– Кара әле, синаитәм. Алдыбыздан бер Будәнә йөгереп бара. Оча алмый бугай ул. Әйдә, шуны тотыйкчы, кайткач суярбыз, Будәнә итен бик



Илдар Юзеевның

сезнең өчен язган
кайбер китаплары

Пони малае Җирәнкәй 1967
Сакаллы маэмай («Салават күпере» китапханәсе)
Аю сатам – кем ала? 1999
Карга баласы Каркылдык 1999

Рәссам Светлана Ибраһимова

Кадерле дуслар!
Журналның урта битен ипләп кенә алып, кара сызыклар буенча кисегез, сары сызыклар буенча бөкләгез дә килеп чыккан кисәкләрне, бит саннарына карап, китап итеп җыегыз. Булгач-булгач, чын китап булсын – уртасын ике урыннан төпләп куегыз.

©«Салават күпере» китапханәсе.





ТАБЫЛДЫК


– Ишеттегезме, мәктәпкә
Нәрсә алып кайтканнар?
– Фәнис, Данис тау буеннан
Мамонт тешен тапканнар!
– Нигә соң ул бик бәләкәй?
– Авызыңны ябып тор!
– Аның бит баласы да була,
Бәлки, нәни мамонттыр.
– Безне миллион еллар көткән
Кыйммәтле табышны без,
Бер тиен акча алмыйча,
Мәктәпкә багышлыйбыз!
– Күрсәтегез урамдагы
Һәрбер кызга, малайга!




Зур-зур китаплар укырсыз
Минем кебек зур булгач.
Бу дөньяда китаптан да
Шәп табылдык табылмас.


КАРБЫЗ БЕЛӘН ФАРВАЗ

Фарваз карбыз ашаган.
Карбыз бик тә ошаган.
Берне, өчне ашаган,
Берчак арта башлаган.
Кайсы карбыз, кайсы Фарваз?
Ни әйтсәң дә ышанам.
Карбыз кемгә охшаган?
Ул Фарвазга охшаган.
Әйт, кемне кем ашаган?



– Табылдыкны күрергә дип,
Килгән Мәмәт бабай да!
– Бик зур рәхмәт, аны эзләп,
Кайда гына йөрмәдем...
Ясалма тешләрем өчен
Бик күп акча түләдем.
«Кыйммәтле табылдык» дигәч,
Тиз генә монда чаптым.
Сез мамонт тешен тапкансыз,
Мин Мәмәт теше таптым!





ЧЫПЧЫК БӘЙРӘМЕ

Чырык-чырык-чырык чырлыйбыз,
Үзебезнең көйгә җырлыйбыз:
Бездә бүген чыпчык бәйрәме,
Син дә кушыл безгә, әйдәле!


Озын кыштан исән-сау чыктык,
Салкын көннәрендә чыныктык.
Бездә бүген чыпчык бәйрәме,
Син дә кушыл безгә, әйдәле!

Чырык-чырык-чырык чып-чырык,
Без унике... утыз... йөз кырык.
Бездә бүген чыпчык бәйрәме,
Син дә кушыл безгә, әйдәле!

Тавыш сандугачка иш түгел,
Ямьле язда җырлый ич күңел.
Бездә бүген чыпчык бәйрәме,
Син дә кушыл безгә, әйдәле!

РӘСЕМНӘР КҮРГӘЗМӘСЕНДӘ

Күргәзмәдә иң күп мактау
Эләккәндер Рәсимгә.
Дусты Нәсим башсыз калды
Чыккан фоторәсемдә.
Барсы да хуплый Рәсимне:
«Төшергәнсең бик дөрес,
Нәсим математикадан
«Икеле» алган көн ич!»





КЕМНӘР НИГӘ ШАТЛАНГАН

Рәсим нигә шатланган?
Ул ишеккә атланган.
Нәсим нигә шатланган?
Ул понига атланган.
Вәсим нигә шатланган?
Ул дөягә атланган.
Ясир нигә шатланган?
Ул чаптарга атланган.
Касыйм да менеп атланган...
Кара син аны, кара:
Әтисенең җилкәсендә
Үкереп елап бара.

МАКАЙ БЕЛӘН АКБАЙ

Макай – чанада яткан.
Акбай – чананы тарткан.
Макай – мәктәптән качкан –
Акбай – букчасын капкан.
Макай – төнен йоклаган.
Акбай – аны саклаган.
Макай – батмый чак калган.
Акбай – аны коткарган.



Акбай – чирли башлаган.
Макай – аны ташлаган.
Акбай – салкында туңа.
Макай – җылыда куна.
Кочакладым Акбайны:
«Оныт, – дидем, – Макайны!»



* * *

– Лачын! – диләр, канат кагып, горур очканга.
Лачын булсам, җирне-күкне кочар идем.
Мин – татар баласы.
– Ут шикелле! – диләр, кулы тисә – эш яна.
Ут булсам мин мәңге сүнмәс идем!
Мин – татар баласы.

Лилия Гайнуллина.
Баулы, Кызыл Яр.



* * *

Һәр кешегә үзенең туган иле, үзе туып үскән авылы кадерле. Габдулла Тукай шигырендәгедәй, үзенең газиз әнкәй теле якын. Һәр татар кешесе шул әнкәй теле белән гомер буе сөйләшә, аралаша. Мәктәптә нинди генә телләр өйрәтмиләр: рус, инглиз, француз телләре... Әмма нинди генә телләр өйрәтсәләр дә, безнең өчен иң якын тел – татар теле. Миңа унике яшь. Мин – татар баласы. Мәктәптә инглиз, рус телләрен өйрәнәм. Ләкин татар телен күбрәк яратам. Татар халкының тарихын кызыксынып укыйм.

Мин газиз, татар телен яратам, хөрмәт итәм һәм киләчәктә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булырга хыялланам.

Миләүшә Гарифуллина.
Балтач, Борнак.



– «Кәҗә»гә атландым! – диеп
Ник мактаныйм, мактанмыйм.
Әти ат алып кайткачтын,
Атланамын атка мин!

(Казан)



– Өстәлдәге тәм-томнарны
Сыпырыплар салдылар.
Тагын ризык эзләргә
Миңа гына калды ла...

(Казан)



– Эшем бетте, күптән инде
Әзерләп куйдым табын.
Кунакларны көтә-көтә,
Кыланчыкланган чагым!

(Казан)





– Маймыл безнең беләнме,
Әллә без маймыл белән...
Ничек булса шул булды –
Сурәткә төштек менә.

(Казан)



– Ковбойлар заманыннан
Бер истәлек бу, олан...
Александра – леди,
Мин шериф булам!

(Казан)

Кояш чыксын күңел күгендә

«Исәнме, Кыш бабай!

Мин сине бик яратам һәм сагынып көтеп алам. Менә Яңа ел да җитте. Алда тагын бәйрәмнәр – 23 Февраль, 8 Март. Ләкин минем һәм энемнең бәйрәм итәргә мөмкинлегебез юк. Без ике бүлмәле фатирда ике гаилә яшибез. Барысы 8 кеше. Әтием – икенче группа инвалид, гел авырый. Әни генә эшли. Әмма аңа акчаны бик аз бирәләр. Фатир да бирмиләр. Кыш бабай, зинһар хәлебезгә керсәгез, ике теләгемне үтәсәгез иде. Бәйрәмнәрдә кияргә күлмәгем юк. Минем дә матур күлмәк киясем килә. Икенче теләгем – безгә аерым фатир алырга булышсагыз иде».


Түбән Кама шәһәреннән 9 яшьлек Айгөл Миннебаева Кыш бабайга язган бу хатын безгә җибәргән. Без аны укыдык та кызга күлмәк алырга хәл кадәри ярдәм иттек. Айгөлнең күңел күге аз гына булса да яктырып китмәсме? Бәлки хатны югары урыннарда эшләүче абый-апалары да укыр. Кызның моң-зарларын алар да ишетер.

Айгөл, киләчәккә ышанычыңны югалтма. Туасы һәр көн сиңа шатлык-куанычлар гына китерсен.









Яна Иванова, 6 яшь.
Кукмара районы, Нырты совхозы.



Илфинә Гайнетдинова, 8 яшь.
Әтнә районы, Күлле-Киме авылы.



Ләйсән Сәлахова, 9 яшь.
Азнакай.


Кадерле редакция!

Мин сезгә әниемнең рәсемен җибәрәм. Минем әнием әлегә авырый. Ләкин мин ышанам: ул элеккечә аягына басар. Һәм мин әнине шатландырыр өчен рәсем җибәрәм. Әни, мин сине яратам һәм бәйрәм белән, туган көнең белән котлыйм.

Кызың Ләйсән.



Эльза Җамалетдинова, 6 яшь.
Буа шәһәре.



Илдар Хаҗиев, II сыйныф.
Саба районы, Өтернәс авылы.



Зөлфия Тимергалиева, II сыйныф.
Саба районы, Өтернәс авылы.



Алсу Ибраһимова, 6 яшь.
Ижау шәһәре.



Гөлзада Ганиева, III сыйныф.
Саба районы, Туктар авылы.



Алсу Нигъмәтуллина, 10 яшь.
Балтач районы, Сәрдегән авылы.



Азат, Мырный



Асия бер фәннән дәрес хәзерләгәндә карандашын 5 мәртәбә өстәл астына төшереп җибәрә. Энесе Азат Асия апасыннан 2 яшькә кечерәк, аңа 8 тула. Малай исә карандашын өстәл астына апасының яшенә караганда ике тапкыр күбрәк төшерә.

Азат карандашны ничә мәртәбә төшерә?

Өстәл астына төшкән карандашны 11 мәртәбә иелеп Азат үзе ала. Калганнарын Мырный кушаматлы шаян песи алып бара. Шуннан соң песи Асия янына килә дә: «Мин 10 тапкыр Азатның карандашын алып бирдем», – дип мактана.

Мырный кушаматлы песи саный беләме?

Азат карандашы артыннан өстәл астына кергәндә Мырный 3 мәртәбә урындык астына башын бәрә: чыкканда бу хәл 5 тапкыр кабатлана. Песи башын бәргән саен ярыктан карап торучы ике тычкан кычкырып көлеп куя.

Тычканнар ничә мәртәбә көлә?



Һәм тычканнар

Көлгән саен бер тычканның кесәсеннән 7 бөртек, икенчесенекеннән тагын 7 бөртек ашлык коела. Алар аның 9ын бергәләшеп җыеп алалар да кабып йоталар.
Ничә бөртек идәндә тәгәрәп кала?

Бер бөртек ашлык көзге уңыш вакытында 5 башак арыш бирә. Ә бер башакта 15 бөртек арыш булса, тычканнар барлыгы күпме уңыш әрәм иткәннәр?

Бу хәлгә түзеп тора алмаган Мырный тычканнарга ачулана башлый. Ул ярык янына килә дә берсен эләктереп ала. Мырный тырнагына эләккән тычкан «чи» дип 8 мәртәбә кычкыра, качып киткәне аңа караганда 3 тапкыр артыграк чиный.
Бу ике тычкан ничә мәртәбә «чи» дип кычкыра?

Тычканнарның тавышы Азатка дәрес хәзерләргә комачаулый. Ул әтисеннән ярыкны томалап куюын үтенә. Әтисенең вакыты булмый. Ул Азатның кулына чүкеч тоттыра һәм 4 кадак бирә. Һәр кадакка икешәр мәртәбә сукканнан соң ярык томалана.
Азат чүкече белән ничә мәртәбә селтәнә?

Рәссам Илдар НӘФИЕВ





Башваткычлар




Монда нинди сүзләр яшерелгән?



Әнисен котларга җыенган бу малайга иң кыска юлны табыш.



Кызчык кулындагы чәчәкләрдән бер-берсенә охшаганнарын тап.



Бу рәсемдә «М А Ш И Н А» яшерелгән.

Такмаклар

Ике куян очып йөри
Мәчет манарасында.
Ала карга бозаулаган
Капка баганасында.

Чуар тавык суга бара,
Аякта киез ката.
Шул вакытта оялмыйча
Ата каз йоклап ята.

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Салават күпере

2-3(144-145) — 2002

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ һӘМ РЕДАКЦИЯ ЖУРНАЛЫ
1990 елның март аеннан бирле чыга.

"Салават купере" ежемесячный журнал Министерства связи РТ, правления Союза писателей РТ и редакции. На татарском языке. Основан в 1990 году.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта
Лилия ЗОЛОНДИНОВА рәсемнәре.

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиесе. Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Производствога бирелде 1.3.2002 ел.
Басарга кул куелды 1.3.2002 ел.
Кәгазь форматы 84x108 1/16.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басыла.
Тиражы 14948 данә. Заказ Б-117.
Бәясе килешү буенча.

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

Ләбиб Лерон

Әни бәйрәме

Айсылу да уянган... Күр:
Бәхтияр дә уянган!
Бишектәге Ләйләгөл дә
Уянганга куанган...

Уянганга куанганга
Бер сәбәп бардыр әле?!
Бар икән шул... Бүген, бүген...
Бүген – Әни бәйрәме!

Әбинең дә, бабайның да
Авызлары җырылган.
Әти, абый, чәчәк тотып,
Тора табын кырында.

Ник елмая алар бүген?
Белсәң, безгә әйт әле?
– Ник әйтмәскә! Бүген, бүген...
Бүген – Әни бәйрәме!

